**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге Советы өченче чакырылыш утырышы**

**Карары**

**08 май** **№ 146** **Алан авылы**

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлегенең 2018 елның 16 маенда 100 нче санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларына, сайланып куелган вазыйфаи затларга һәм муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән 131 санлы карары нигезендә, 2013 елның 28 декабрендәге «Иминият пенсияләре турында»гы 400 санлы Федераль законга туры китереп, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге Советы карар **кабул итте:**

1.Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге Советының 2018 елның 16 маенда 100 нче санлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларына, сайланып куелган вазыйфаи затларга һәм муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләү шартлары турындагы Нигезләмә» карарына (2018 елның 20 нче сентябрендә 104нче санлы; 2018 елның 09 нчы октябрендә 114нче санлы; 2018 елның 20 нче декабрендә 125нче санлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларына, сайланып куелган вазыйфаи затларга һәм муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә:

II бүлектә:

А) 3 пунктны түбәндәге тәртиптә бирергә:

«3. Алан авыл җирлеге башлыгына, айлык акчалата түләүдән һәм еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр түләнә торган акчадан тыш, өстәмә айлык акчалата кызыксындыру, тиешле елларны эшләгән өчен айлык түләү, муниципаль хокукый актлар нигезендә премияләр дә түләнә ала.»

Б) түбәндәге эчтәлектәге 6. 1. пункт белән тулыландырырга:

«6.1. Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге башлыгына ай саен бер мең сум күләмендә премия түләнә.»

VII бүлектә:

А) 21 пунктта «айлык акчалата бүләкләү» сүзләреннән соң «һәр ай саен акчалата бүләкләү һәм акчалата кызыксындыру» сүзләре белән тулыландырырга;

Б) 25 пунктны түбәндәгечә бирергә:

«25. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия «Иминият пенсияләре турында»гы Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясен алу хокукын бирә торган яшькә җиткәч, йә вакытыннан алда картлык буенча иминият пенсиясе яисә инвалидлык буенча иминият пенсиясе билгеләгәндә исәпләнә. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия гомерлеккә билгеләнә һәм ай саен түләнә.»

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль районы
Алан авыл җирлеге башлыгы Ә.Г.Хаҗиев